**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ТЕТЮШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422370 г.Тетюши, ул.Малкина, 39

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур, 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru

ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.04.2025 № 217

**Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының "бакчачылык алып бару өчен гражданнар милкенә (арендага) җир кишәрлеге бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 18.07.2019 ел, № 533 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының 18.07.2019 ел, № 533 карары белән расланган бакчачылык алып бару өчен гражданнар милкенә (арендага) җир кишәрлеге бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1) 2 бүлекнең 2.3 пунктындагы 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«2) җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән затка җир кишәрлеген бирүне алдан килештерүдән баш тарту хакында. Бу очракта вәкаләтле орган мондый карар кабул ителгән көннән алып дүрт айдан да соңга калмыйча сорала торган җир кишәрлеген төзүне яисә аның чикләрен төгәлләштерүне тәэмин итә, җир кишәрлеген сату буенча аукцион яисә җир кишәрлеген алдан килештерү турындагы гаризада күрсәтелгән максатлар өчен җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион үткәрү турында Карар кабул итә һәм аукцион уздыру турында».

2) 2 бүлекнең 2.9 пунктындагы 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«2) җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән затка җир кишәрлеген бирүне алдан килештерүдән баш тарту хакында. Бу очракта вәкаләтле орган мондый карар кабул ителгән көннән алып дүрт айдан да соңга калмыйча сорала торган җир кишәрлеген төзүне яисә аның чикләрен төгәлләштерүне тәэмин итә, җир кишәрлеген сату буенча аукцион яисә җир кишәрлеген алдан килештерү турындагы гаризада күрсәтелгән максатлар өчен җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион үткәрү турында Карар кабул итә һәм аукцион уздыру турында».

3) 2 бүлекнең 2.9 пунктындагы 13 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«13) гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата Җир кодексының 39.18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару өчен җир кишәрлеге бирү турында хәбәрнамә урнаштырылган».

3. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

**Җитәкче** **А.А. Гасыймов**